| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2025 г.Казань № 263-31/кс-2025

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2025 - 2027 елларга Лаеш муниципаль районының «Коммунальный сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен ташландык су чыгаруга тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау турында» 18.12.2024 ел, № 600-154/кс-2024 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты Идарәсе утырышының 05.11.2025 ел, №22-ПР беркетмәсе белән билгеләнгән тарифларның гамәлдә булуы кагыла торган муниципаль берәмлекләр исемлеген төгәлләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2025-2027 елларга Лаеш муниципаль районының «Коммунальный сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен ташландык су чыгаруга тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау турында» 18.12.2024 ел, № 600-154/кс-2024 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтада:

1 пунктның 1.1 пунктчасында «Габишево һәм Комлы Кавал авыл җирлекләре кулланучылары» сүзләрен «Габишево, Матюшино һәм Комлы Кавал авыл җирлекләре кулланучылары» сүзләренә алмаштырырга.;

2 нче кушымтада:

1 пунктның 1.1 пунктчасында «Габишево һәм Комлы Кавал авыл җирлекләре кулланучылары» сүзләрен «Габишево, Матюшино һәм Комлы Кавал авыл җирлекләре кулланучылары» сүзләренә алмаштырырга.;

4 нче кушымтада:

2 бүлектә «1ВО – Габишево һәм Комлы Кавал авыл җирлекләре кулланучылары өчен су чыгаруга тариф» сүзләрен «1ВО – Габишево, Матюшино һәм Комлы Кавал авыл җирлекләре кулланучылары өчен ташландык су чыгаруга тариф» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә «1ВО – Габишево һәм Комлы Кавал авыл җирлекләре кулланучылары өчен су чыгаруга тариф» сүзләрен «1ВО – Габишево, Матюшино һәм Комлы Кавал авыл җирлекләре кулланучылары өчен ташландык су чыгаруга тариф» сүзләренә алмаштырырга;

6 бүлектә «1ВО – Габишево һәм Комлы Кавал авыл җирлекләре кулланучылары өчен су чыгаруга тариф» сүзләрен «1ВО – Габишево, Матюшино һәм Комлы Кавал авыл җирлекләре кулланучылары өчен ташландык су чыгаруга тариф» сүзләренә алмаштырырга;

7 бүлектә «1ВО – Габишево һәм Комлы Кавал авыл җирлекләре кулланучылары өчен су чыгаруга тариф» сүзләрен «1ВО – Габишево, Матюшино һәм Комлы Кавал авыл җирлекләре кулланучылары өчен ташландык су чыгаруга тариф» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В.Гайнетдинов